| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 2 октябре № 21

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 сентябрендә кабул ителгән 21 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмәне раслау турында» карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Иске Шөгер авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Иске Шөгер авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 сентябрендә кабул ителгән 21 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмәне раслау турында» карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск районы Иске Шөгер авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында “Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карараның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Совет Рәисе Л.М.Шиһапова